# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 248-35 «22» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 12 июлендәге «Азнакай муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында» 167-22 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында
(2017 елның 9 ноябрендәге 148-22 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясына 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән үзгәрешләр кертү сәбәпле, шулай ук Азнакай шәһәр прокурорының 2019 елның 28 февралендәге 02-08-02/201-2019 номерлы протестын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 12 июлендәге «Азнакай муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында» 167-22 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү тәртибенә (2017 елның 9 ноябрендәге 148-22 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1,3 пунктта «дача төзелеше»сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә: http://aznakayevo.tatar.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин